*Исправления не допускаются*

**Итоговый балл** ________ ___________________ **Шифр** _____________
(подпись председателя жюри)

**Межрегиональная предметная олимпиада Казанского федерального университета по предмету «Татарский язык»**
**Очный тур**
**2016-2017 учебный год**
**9 класс**

**I. Рус телендәге гыйбарәләрнең татарча эквивалентларын языгыз. /** Напишите эквиваленты выражений на татарском языке, соответствующие русским.(10 баллов).

1) **Пустить пыль в глаза -**
2) **Не выдерживать критики -**
3) **Кормить соловья баснями -**
4) **На роду написано -**
5) **Отдать должное –**
6) **Високосный год -**
7) **Горячая пора -**
8) **Быть совершеннолетним -**
9) **Не упускать шанса -**
10) **Красавчик -**

**II. Анаграммалар төзегез. /** Составьте анаграммы (10 баллов).

1) **АШЛЫК –**
2) **БАЗАР –**
3) **БАКЧА -**
4) **АВТОР –**
5) **АТЛАС –**

**III. Сүз басымын билгеләгез. /** Обозначьте в словах ударение. (10 баллов)

Кадыйр бүген чаңгыда җил белән узышырга булды. Нигә дисезме? Чөнки авылда аның белән узышмаган малай калмады инде. Җил дә аны барыбер уза алмас. (*Н.Каштановтан*)

**IV. Сүзтезмәләрне табыгыз, һәрберсенә тулы билгеләмә бирегез. / Найдите** словосочетания и дайте им полное определение. (10 баллов)

Малайлар бик сорагач, әнигә әйтмичә, бакчага кердем дә көнбагышларның зурларын өзеп алдым, аларны малайларга алып чыктым.

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

**V. Башваткычны чишегез. Тел белеме терминнарын языгыз./** Решите кроссворд. Напишите лингвистические термины (15 баллов).

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | **А** | | | **З** | | | | | | | | |
| 2 | **С** | | | | **К** | | | | | | | |
| 3 | **Җ** | | | | **Ә** | | | | | | | |
| 4 | **Х** | | | | **Ф** | | | | | | | |
| 5 | **Ы** | | | | **К** | | | | | | | |
| 6 | **Ф** | | | | | **А** | | | | | | |
| 7 | **Ж** | | | | | **Н** | | | | | | |
| 8 | **С** | | | | | **Т** | | | | | | |
| 9 | **А** | | | | | | **М** | | | | | |
| 10 | **К** | | | | | | **Ә** | | | | | |
| 11 | **С** | | | | | | | **Ә** | | | | |
| 12 | **А** | | | | | | | **А** | | | | |
| 13 | **М** | | | | | | | **А** | | | | |
| 14 | **М** | | | | | | | | **А** | | | |
| 15 | **Л** | | | | | | | | | | | **Я** |

**VI. Татар теленең орфографик принципларын языгыз. Һәр принципка 2шәр мисал китерегез. /** Напишите какие орфографические принципы существуют в татарском языке. Приведите каждому по 2 примера (10 баллов).

**VII. Татар теленең сүзлек составы турынданиләр беләсез? Шул турыда языгыз. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез.** / Что Вы знаете о лексическом составе татарского языка? Напишите об этом. Обоснуйте свое мнение примерами.(15 баллов).

**VIII. "Матур кешеләр нинди була?" дигән сорауга җавап биреп, 70 сүздән ким булмаган инша язгыз. Фикерегезне дәлилләп, 2дән ким булмаган дәлил китерегез.** /Напишите сочинение (не менее из 70 слов) ответив на вопрос " Какими бывают красивые люди?" . Приведите не менее 2 довыда – примера (20 баллов).

*Исправления не допускаются*

**ОТВЕТЫ.**

**I. Рус телендәге гыйбарәләрнең татарча эквивалентларын языгыз. /** Напишите эквиваленты выражений на татарском языке, соответствующие русским.(10 баллов).

11) **Пустить пыль в глаза** - сабын күбеге очыру *яки* күзгә төтен җибәрү
12) **Не выдерживать критики** - серкәсе су күтәрмәү *яки* сүз күтәрмәү
13) **Кормить соловья баснями** - сүз белән сыйлау
14) **На роду написано** - тәкъдирдә язылган *яки* ходай язган
15) **Отдать должное –** тиешле бәясен бирү *яки* тиярен бирү.
16) **Високосный год** - кәбисә ел
17) **Горячая пора -** урак өсте *яки* уттай эш өсте
18) **Быть совершеннолетним** - балигъ булу
19) **Не упускать шанса -** форсаттан файдалану *яки* мөмкинлекне кулдан ычкындырмау
20) **Красавчик** - чибәр егет

**II. Анаграммалар төзегез. /** Составьте анаграммы (10 баллов).

6) **АШЛЫК –** алкыш
7) **БАЗАР –** абзар
8) **БАКЧА -** чабак
9) **АВТОР –** товар
10) **АТЛАС –** салат

**III. Сүз басымын билгеләгез.** / Обозначьте в словах ударение. (10 баллов)

КадЫйр бүгЕн чаңгыдА җИл белӘн узышыргА булдЫ. НИгә дисЕзме? ЧӨнки авылдА анЫң белӘн узЫшмаган малАй кАлмады индЕ. ҖИл дә анЫ бАрыбер узА алмас. (Н.Каштановтан)

**IV. Сүзтезмәләрне табыгыз, һәрберсенә тулы билгеләмә бирегез. / Найдите** словосочетания и дайте им полное определение. (10 баллов)

Малайлар бик сорагач, әнигә әйтмичә, бакчага кердем дә көнбагышларның зурларын өзеп алдым, аларны малайларга алып чыктым.

ҖАВАП:
Бик сорау –
Әнигә әйтмәү –
Бакчага керү-
Көнбагышның зурлары –
Аларны алып чыгу-
Малайларга алып чыгу –
Әйтмичә алып чыгу –
Зурларын өзеп алу -
Әйтмичә керү-
Сорагач керү -

**V. Башваткычны чишегез. Тел белеме терминнарын языгыз./** Решите кроссворд. Напишите лингвистические термины (15 баллов).

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **1** | **А** | **в** | **а** | **З** | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2 | С | ы | з | ы | К | | | | | | | |
| 3 | Җ | ө | м | л | Ә | | | | | | | |
| 4 | Х | ә | р | е | Ф | | | | | | | |
| 5 | Ы | м | л | ы | К | | | | | | | |
| 6 | Ф | о | н | е | м | А | | | | | | |
| 7 | Ж | а | р | г | о | Н | | | | | | |
| 8 | С | ы | й | ф | а | Т | | | | | | |
| 9 | А | н | т | о | н | и | М | | | | | |
| 10 | К | и | с | ә | к | ч | Ә | | | | | |
| 11 | С | ү | з | т | е | з | м | Ә | | | | |
| 12 | А | н | т | и | т | е | з | А | | | | |
| 13 | М | е | т | а | ф | о | р | А | | | | |
| 14 | М | о | р | ф | е | м | и | к | А | | | |
| 15 | Л | е | к | с | и | к | о | л | о | г | и | Я |

**VI. Татар теленең орфографик принципларын языгыз. Һәр принципка 2шәр мисал китерегез.** / Напишите какие орфографические принципы существуют в татарском языке. Приведите каждому по 2 примера (10 баллов).

1) фонетик принцип – ишетелгәнчә язылыш ( китап, урам);
2) морфологик принцип – морфемаларның бөтенлеген саклап язу ( тозсыз, унбер);
3) тарихи-традицион принцип - беренчел язылыш кагыйдәсен саклап язу (икътисад, бала-чага);
4) график принцип – алынма сүзләрне нигез телдәгечә язу (компьютер, монитор);
5) дифференцияләнгән язылыш – мәгънә аермасын саклау өчен кулланыла торган язылыш төре ( өч почмак – өчпочмак, күпмәгънәле – күп мәгънәле)

**VII. Татар теленең сүзлек составы турында ниләр беләсез? Шул турыда языгыз. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез.** / Что Вы знаете о лексическом составе татарского языка? Напишите об этом. Обоснуйте свое мнение примерами.(15 баллов).

Татар теленең сүзлек составында актив һәм пассив лексика бар. Лексик фонд гомумкулланылыштагы сүзләр, һөнәрчелек лексикасы, жаргон һәм арго сүзләр, китаби берәмлекләр, терминнарны һ.б. ларны тәшкил итә. Сүзлек составында искергән һәм яңа сүзләр дә бар.

**VIII. "Матур кешеләр нинди була?" дигән сорауга җавап биреп, 70 сүздән ким булмаган инша языгыз. Фикерегезне дәлилләп, 2дән ким булмаган дәлил китерегез.** /Напишите сочинение (не менее из 70 слов) ответив на вопрос " Какими бывают красивые люди?" . Приведите не менее 2 довыда – примера (20 баллов).

| № | Сочинениене бәяләү критерийлары | Баллар |
|---|---|---|
| *I* | ***Иншаның эчтәлеге*** | |
| | Язманың эчтәлеге темага туры килә. Эчтәлеге тулысынча ачылган. Икедән артык дәлил бирелгән. | 4 |
| | Язманың эчтәлеге, нигездә, темага туры килә. Эчтәлеге ачылган. 1-2 гомуми дәлил бар. | 3 |
| | Язманың эчтәлеген бирүдә җитди ялгышлар бар. 1 дәлил бар. | 2 |
| | Язманың эчтәлеге ачылмаган<br>**яки**<br>мисал буларак дәлил язылмаган. | 0 |
| *II* | ***Иншаның тел ягы*** | |
| | **Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге, язу** | |

| | | |
|---|---|---|
| | **эзлеклелеге** | |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана:<br>– логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган;<br>– абзацларга бүленештә хаталар юк. | 2 |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана,<br>**ләкин**<br>1 логик хатасы бар,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **1** урында хата бар. | 1 |
| | Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар,<br>**ләкин**<br>логик хаталарның саны 1 дән артык,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **2** урында хата бар. | 0 |
| | **Төгәллек һәм сөйләм матурлыгы** | |
| | Язмада фикер төгәл, төрле грамматик формалар кулланылган. | 2 |
| | Язмада фикер төгәл,<br>**Ләкин** бер генә төрле сөйләм калыпларыннан файдаланылган,<br>**яки**<br>язмада төрле грамматик формалар кулланылган,<br>**ләкин** фикер төгәллеге бозылган. | 1 |
| | Сүз байлыгыннан тиешенчә файдалана алмаган, бер үк төрле җөмлә калыпларын гына кулланган. | 0 |
| ***III*** | ***Грамоталылык*** | |
| | **Орфографик нормаларның үтәлеше** | |
| | Орфографик хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | Хатасы 2 дән артык түгел. | 2 |
| | 3-4 хата җибәрелгән | 1 |
| | Хаталарының саны 4 тән артык | 0 |
| | **Пунктуацион нормаларның үтәлеше** | |
| | Пунктуацион хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | 1-3 хатасы бар. | 2 |
| | 4-5 хатасы бар. | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| | **Тел нормаларының үтәлеше** | |
| | Грамматик хаталары юк | 2 |
| | 1–2 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 2 дән артык | 0 |
| | **Сөйләм нормаларының үтәлеше** | |
| | Сөйләмгә кагылышлы 1 генә хатасы бар | 2 |
| | **2–3** хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны **3** тән артык | 0 |
| | **Этикага кагылышлы нормаларның үтәлеше** | |
| | Этикага кагылышлы хаталары юк | 1 |
| | Хаталары бар (1 һәм 1дән күбрәк) | 0 |
| | **Язмада фактларны бирүдәге төгәллекнең үтәлеше** | |
| | Фактик хаталары юк. | 1 |
| | Фактик хаталары бар. | 0 |

*Исправления не допускаются*

| Язма эш өчен максималь балл | 20 |
| --- | --- |